МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.08.2021 г.Казань № 567

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 25 августында 7873 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 6 августындагы 567 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691, 24.02.2021 №102, 21.05.2021 №331 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектәге 1.3.6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү (алга таба – субсидия-ташлама).

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

2.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсе.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча рәсми мөрәҗәгать җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) алынган көннән алып биш эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Субсидия-ташлама билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларда күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләгәнчегә кадәр туктатыла, ләкин дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көннән дә артыгракка түгел.

2.4.3. Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә хәбәр ителә.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта *яки башка* кредит учреждениесендә ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, субсидия-ташлама бирү турында гариза:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.

3) әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә эш урыныннан субсидия-ташлама алу хокукы турында белешмә дә тапшыра.

4) әлеге Регламентның 1.2 пунктының 41 пунктчасында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән никахны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

5) 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарында каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыра.

6) хезмәт ветераннары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүдә субсидия-ташламалар бирү турында» 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләүдә субсидия-ташламалар бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең (алга таба – 126 номерлы нигезләмә) 1 пунктындагы өченче абзацында һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны өстәмә тапшыра.

2.5.2. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.4. Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә танықланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре тарафыннан таныклана.

2.5.5. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслаучы документ, гамәлдәге законнарда каралган очракларда мөрәҗәгать итүченең субсидия-ташлама алу хокукын раслаучы документ күрсәтә.

2.5.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.5.7. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өчен) урнаштырылган.

2.5.8. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә танықланган булырга тиеш.

2.5.9. Мөрәҗәгать итүчеләр, гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын растарга кирәк.

2.5.10. Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм

жирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында; инвалидлык билгеләнүе турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

инвалидка (инвалид балага) айлык акчалата түләү билгеләү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

салымнар, җыемнар һәм мәҗбүри башка түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бурыч булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен).

2.6.2. Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чын булуын раслау турындагы белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.4. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.5. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе.

2.7.2. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрдә салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

Татарстан Республикасы законнарында яки федераль законнарда билгеләнгән башка нигезләрдә, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, эшчеләр бистәләрендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшли һәм яши торган гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 июнендәге 251 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә, эшчеләр бистәләрендә (шәһәр тибындагы поселокларда) эшли һәм яши торган гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибенең 15 пункты таләпләрен исәпкә алып, әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-40 пунктчаларында күрсәтелгән затларның социаль ярдәм чараларын алуы;

субсидия-ташлама алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылуы;

әлеге Регламентның 1.2 пунктының 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри башка түләүләр буенча субсидия-ташлама билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән башлап 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычлар булуы;

хезмәт ветеранының уртача айлык кереме 20 000 сумнан артып китүе;

хезмәт ветеранының төрләренең исемлеге 126 номерлы нигезләмәдә күрсәтелгән керемнәрнең булмавы;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

2.9.1. Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

2.11.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү өчен кирәкле документлар исемлегенә карата таләпләр. Шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны

социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә карата да

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) яки күрсәтеп булмау мөмкинлеге

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итәлә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнеш таләп ителми.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-

ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин.

2.16.5. Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 нче бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.9 пункт өстәргә:

«3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелми.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урын һәм коммуналь
хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-
ташлама билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Форма

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №_ бүлегенә

________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА

«__» ___________ 20 ___ ел.

Мин, ________________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

яши торган адрес:

______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең индексын, телефонын, электрон адресын күрсәтеп почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе: _____________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләвегез турында үтенәм

______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:
счетка күчерү юлы белән

______________________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлеге аша ____________________________________________________
(дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның яисә аның законлы вәкиленең почта аша җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган мәгълүматларның төгәллеге, аларның үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплылык һәм торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында хәбәрдар.
Мөрәҗәгать итүче:___________________________ _________ «__»______ 20__ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.) (имза)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш

тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында мәгълүмат алуга риза

______________________________________________________________________________.

(почта адресы буенча хат белән, смс-хәбәр итеп, электр почта адресы буенча)

«__»________ 20__ ел. Имза _______________

Яңа вакытка социаль ярдәм чараларын автомат рәвештә билгеләү белән килешәм.

Мөрәҗәгать итүченең имзасы ________________________________

(хезмәттән файдаланучы булып хезмәт ветераны торган очракта тутырыла)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел. _________ ______________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________________.

Аеру линиясе

Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте ___________ _________ _____________ ______ 20__ ел.

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшьтән җиде яшькәчә балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 25 апрелендәге 263 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.07.2020 №503, 02.10.2020 №692, 09.06.2021 №410 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Өч яшьтән җиде яшькәчә балага айлык акчалата түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектәге 1.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

2.1.1. Өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү (алга таба – айлык акчалата түләү) билгеләү.

2.2. Башкарма хакимият органы (учреждениесе) атамасы

2.2.2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы бүлекчәсе.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Айлык акчалата түләү билгеләү (яңадан исәпләү) (билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту) турында карар дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән рәсмиләштерелә һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресына һәм мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына;

телефонга смс-хәбәр итеп.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Айлык акчалата түләү билгеләү (яңадан исәпләү) (билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту) турында карар, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып, 10 эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Айлык акчалата түләү билгеләү (яңадан исәпләү) (билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту) турында карар кабул итү чоры арттырыла:

гариза «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан яки «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып тапшырылган очракта яки шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларның тулы булмаган комплекты тапшырылган очракта – 10 эш көненә;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратыла торган мәгълүматлар килмәгән очракта – 20 эш көненә.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризада һәм (яки) документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнгән очракта, айлык акчалата түләү билгеләү яки билгеләүдән баш тарту турындагы карарны кабул итү срогы биш эш көненә туктатыла.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү айлык акчалата түләүне билгеләү (яңадан исәпләү) (билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «3 яшьтән 7 яшькәчә балага айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү тәртибенә карата төп таләпләр, әлеге айлык түләүне билгеләү өчен кирәкле документларның (белешмәләрнең) якынча исемлеген һәм аны билгеләү турындагы гаризаның типлаштырылган формасын раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 384 номерлы карары белән расланган форма буенча айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге пункт таләпләренә туры китереп имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

2) бала туу турында документның күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – туу тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

3) гаилә әгъзасының үлүе турындагы документ күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – вафатлык тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

4) өйләнешү (аерылышу) турында документның күчермәсе һәм аның нотариаль таныкланган тәрҗемәсе – өйләнешү (аерылышу) тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта;

5) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзалары мөлкәтендә Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүве мөмкин булмаган хроник чирләрнең авыр формалары исемлегендә каралган хроник чирнең авыр формасыннан интегә торган мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзасы биләп торган, билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын (торак йортның бер өлеше; фатирның бер өлеше; бүлмә) булуы турында документ күчермәсе;

6) 23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү оешмасында көндезге уку формасы буенча белем алу факты турында документ күчермәсе;

7) 23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү

оешмасында көндезге уку формасы буенча белем алган очракта стипендияне алып бетермәү факты турындагы документ күчермәсе;

8) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан өч айдан артык дәвалану факты, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыра алмаулары турында документ күчермәсе;

9) мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының тулы дәүләт тәэминатында булуы турында документ күчермәсе (опекадагы балалардан тыш);

10) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзаларының чакырылу буенча хәрби хезмәт үтүе турында, шулай ук хәрби һөнәри оешмада һәм югары белем бирүче хәрби мәгариф оешмасында белем алучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән затның хәрби хезмәткәр статусы турында документ күчермәсе;

11) мөрәҗәгать итүченең яисә аның гаилә әгъзаларының суд карары буенча мәҗбүри дәвалауда булуы турында документ күчермәсе;

12) мөрәҗәгать итүчегә яки аның гаилә әгъзаларына карата сак астына алу рәвешендә чикләү чарасын куллану турында документ күчермәсе;

13) һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучы затларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга, дини белем бирү оешмаларында укучы югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академик отпуск ялында булу чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре күләме турында белешмә күчермәсе;

14) отставкага чыккан судьяларга гомер буе айлык акчалата түләү күләме турында документ күчермәсе;

15) хәрби хезмәттән, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендәге хезмәттән, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнардагы хезмәттән киткәндә бер тапкыр бирелә торган пособие күләме турында документ күчермәсе;

16) хәрби хезмәт, Россия Федерациясенең җинаять үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарында, федераль куркынычсызлык хезмәте органнарында, дәүләт сагы органнарында, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында, Россия Федерациясе таможня органнарында, Россия Федерациясе илкүләм гвардия гаскәрләрендә, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсендә, шулай ук Россия Федерациясе законнарында хокук куллану эшчәнлеге белән бәйле дәүләт хезмәтен узу күздә тотылган башка органнарда хезмәт итүче (хезмәт иткә) затлар ала торган пенсия күләме турында документ күчермәсе;

17) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшенә кадәр (тулганчы) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшенә кадәр

(тулганчы) балага айлык акчалата түләү тәртибе һәм шартларының (алга таба – Тәртип) 3.6 пунктының икенче абзацында (мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары Россия Федерациясе җинаять үтәтү системасына караган оешмаларның һәм органнарның, федераль иминлек хезмәте органнарының, Россия Федерациясе дәүләт сагы органнарының, эчке эшләр органнарының хезмәткәрләре булып торсалар) һәм җиденче абзацында каралган керемнәр күләме турындагы документ күчермәсе;

18) дәүләт бурычларын яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган, алынган компенсация күләме турында документ күчермәсе;

19) мөрәҗәгать итүче яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан Россия Федерациясеннән читтә алынган керемнәр күләме турында документ күчермәсе;

20) мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында Татарстан Республикасы законнары нигезендә күпбалалы гаилә (алга таба – күпбалалы гаилә) дип танылган гаиләләргә социаль ярдәм итү кысаларында бирелгән «торак» һәм «торак төзелмә» билгеләнеше белән биналар, «торак» һәм «торак урын» билгеләнеше белән бүлмәләр, «торак йорт» билгеләнеше белән биналар, җир кишәрлекләре, шулай ук «Гражданнарга дәүләт яки муниципаль мөлкәттә торган һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан, Ерак көнчыгыш федераль округы составына керә торган җир кишәрлекләрен бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 1 маендагы 119-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре булуы турында документ күчермәсе;

21) мөрәҗәгать итүчегә яисә аның гаилә әгъзаларына теркәлгән, күпбалалы гаиләгә социаль ярдәм күрсәтү кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән автотранспорт (мототранспорт) чарасы булуы турында документ күчермәсе;

22) айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза түләү алучы вәкаләт биргән зат яки түләү алучының законлы вәкилләре тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә бирелгән очракта, ышаныч кәгазенең күчермәсе.

2.5.2. Мөрәҗәгать итүче гаилә әгъзаларының үзләренең персональ белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгы булуын һәм мөрәҗәгать итүченең органга яки оешмага персональ белешмәләрне тапшырганда алар исеменнән эш итү вәкаләтен раслый торган документны (документларны) (ирекле формада) тапшыра.

2.5.3. Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны күрсәтә.

2.5.4. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

2.5.5. Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

2.5.6. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә

күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгече яки күпфункцияле үзәк белгече тарафыннан таныклана.

2.5.7. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә шәхсән, почта юлламасы белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

2.5.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Бердәм порталда урнаштырылган.

2.5.9. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

Үзәк бүлекчәсенә яисә почта аша кәгазьдә;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша.

2.5.10. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

2.5.11. Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм Мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге белешмәләр алына:

бала тууы турында, баланың тууы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

баланың вафат булуы турында, баланың вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

гаилә әгъзасының вафат булуы турында, гаилә әгъзасының вафат булуы тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш;

өйләнешү (аерылышу) турында, өйләнешү (аерылышу) тиешле чит ил дәүләте законнары буенча чит илнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очрактан тыш; баланы опека билгеләнүе турында;

баланың ата-аналары турында;

үзләренә карата гариза бирелгән баланың (балаларның) опекуны турында; ата-аналык хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукларындагы чикләүләрне гамәлдән чыгару турында, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда баланы йолып алу турында;

ата-ананың яки баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләте чикләнгән булуы яисә хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

хезмәт һәм башка бурычларны үтәгән өчен түләү, шул исәптән кызыксындыру характерындагы түләүләр, башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләү, гражданлык хокукы килешүе кысаларында гамәлләр кылган өчен бүләкләү турында;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе Илкүләм гвардиясе гаскәрләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, Россия Федерациясе Президентының Махсус программалар баш идарәсе хезмәткәрләре керемнәре турында;

пенсия, пособиеләр һәм башка шундый ук түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча һәм Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган компенсация характерындагы түләүләрнең суммалары турында;

Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе турында законнарында каралган очракларда вафат булган иминиятләштерелгән затларның хокукый варисларына түләүләр турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керемен исәпләү чорында эшкә сәләтсез затларны карау турында;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә кереме исәпләнгән чорда эшсез яки эш эзләүче статусы булуы турында;

кыйммәтле кәгазьләр белән операцияләр буенча, шулай ук оешма мөлкәтенә идарә итүдә катнашуга бәйле алынган дивидендлар, процентлар һәм башка керемнәр турында;

кредит оешмаларында кертемнәр буенча алынган процентлар турында (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр һәм шәхси практика башкарудан алынган керемнәр турында;

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллану кысаларында алынган керемнәр турында;

авторлык заказы, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә аерым хокукны читләштерү турындагы килешүләр буенча алынган керемнәр турында;

Россия Федерациясе Салым кодексының 217.1 статьясында күрсәтелгән сроктан азрак вакыт эчендә милектә булган күчемсез милекне сатудан, шулай ук мөлкәтне арендага (наемга, поднаемга) бирүдән алынган керемнәр турында;

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы күчемсез милек турында;

Россия Федерациясе гражданинының Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлүе турында;

Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданинының шәхесен таныклый торган, Россия Федерациясе гражданинына элек бирелгән паспортлар турында;

алына торган алиментлар турында (әгәр акчалар түләттерүчегә суд приставлары бүлегенә алиментлар түләттерүгә бәйле эш буенча вакытлыча идарәлеккә күчә торган акчаларны исәпкә алу счетыннан күчерелгән булса);

автотранспорт яки мототранспорт чаралары турында;

чыгарылган елы биш елдан артмаган кече суднолар турында (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача кереме исәпләнә торган чорга мөрәҗәгать итүчене яки аның гаилә әгъзаларын иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итү турында;

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының иректән мәхрүм ителү урыннарында булуы турында;

инвалидлык һәм аның төркеме турында (булган очракта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 1507 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарны һәм башка төр техниканы дәүләт теркәвенә алу кагыйдәләре нигезендә теркәлгән үзйөрешле машиналар һәм башка төр техника турында (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

шәхси счетның иминият номеры турында.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.3. Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.6.4. Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче

тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә электрон рәвешләре элегрәк таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

2) күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү;

3) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

4) мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе;

5) мөрәҗәгать итүче тарафыннан элек бирелгән өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризаның Үзәге бүлекчәсендә булуы, аның буенча карар кабул ителмәгән булуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан яки «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып яки шәхсән мөрәҗәгать итеп гариза тапшырган вакытта

документларның тулы булмаган комплекты тапшырылган очракта;

ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар алынмаган очракта;

мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризада һәм (яки) документларда дөрес булмаган һәм (яки) тулы булмаган мәгълүмат булу факты билгеләнгән очракта.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

үзенә карата гариза тапшырыла торган баланың вафат булуын дәүләт теркәвенә алу;

үзенә карата гариза тапшырыла торган баланың тулысынча дәүләт тәэминатында торуы;

үзенә карата гариза тапшырылган балага ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү яки ата-ана хокукында чикләнү;

түләү алучы гаиләсенең җан башына исәпләгәндә уртача керменең халыкның җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрүе;

үзенә карата гариза алынган баланың сигез яшен тутыруы, Тәртипнең 1.4 пунктындагы өченче абзацта каралган очрактан тыш;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан Тәртипнең 2.1 пунктында саналган документларның Үзәк бүлекчәсенә тапшырылмавы, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның һәм документларның Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән срокларда тапшырылмавы;

Тәртипнең 2.5 пункты нигезендә гаризаны һәм (яки) документларны эшләп бетерү өчен кире кайтару көненнән башлап биш эш көне эчендә мөрәҗәгать итүченең кирәкле гариза һәм (яки) документларны тапшырмавы;

үзенә карата гариза тапшырыла торган балага карата башка законлы вәкилгә айлык акчалата түләү билгеләнү фактының билгеләнүе;

гаризада дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар булуы;

Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән исәп-хисап чорына мөрәҗәгать итүчедә һәм (яки) аның хезмәткә сәләтле гаилә әгъзаларында (18 яшенә җитмәгән балаларыннан тыш) Тәртипнең 3.6 пунктындагы икенче, өченче (пенсияләр өлешендә), дүртенче, җиденче, унберенче, унөченче-унбишенче, унҗиденче абзацларында каралган керемнәрнең булмавы, әлеге чорга туры килә торган түбәндәге очраклардан (аларның җыелмасыннан) тыш:

мөрәҗәгать итүченең яки аның эшли торган гаилә әгъзаларының алты айдан артыграк эшсезлек статусында булуы;

мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзалары өч яшенә җиткәнче бала каравы яисә 18 яшенә кадәрге инвалид-баланы яки балачактан I төркем инвалидны яисә I төркем инвалидны яисә 80 яшенә җитеп, дәвалау оешмасы бәяләмәсе белән даими рәвештә читләр тәрбиясенә мохтаҗ дип танылган өлкән кешене каравы;

23 яшьтән кечерәк мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге форма буенча укуы һәм стипендия алмавы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының 3 айдан артык вакыт дәвамында дәвалануы, шуның нәтиҗәсендә вакытлыча хезмәт эшчәнлеген *башкара* алмавы;

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының хәрби хезмәт узуы (демобилизация көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең яки аның гаилә әгъзаларының ирektән мәхрүм ителүе (иреккә чыгу көненә кадәр өч айдан артмаган чорны да кертеп);

мөрәҗәгать итүченең балигълык яшенә җитмәгән балаларның бердәнбер ата-анасы (законлы вәкиле) булып торуы (булуы);

мөрәҗәгать итүченең яки аның күпбалалы гаиләсендә бер әгъзасының керемнәр алмавы.

Әлеге пунктның уналтынчы-егерме өченче абзацларында күрсәтелгән нигезләр буенча керемнәр булмаган чорлар тулаем бәяләнә. Әлеге нигезләр буенча керемнәр булмаган чор җыеп исәпләгәндә Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән исәп-хисап чорының 10 һәм аннан күбрәк аен тәшкил итсә, түләү билгеләүдән (яңадан исәпләүдән) баш тарту турында карар кабул ителми;

мөрәҗәгать итүчедә һәм айлык түләү билгеләнә торган балада Россия Федерациясе гражданлыгы булмау;

мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында айлык түләү билгеләү өчен мөрәҗәгат итү датасына Россия Федерациясе буенча билгеләнгән, тулаем алганда халыкның җан башына исәпләгәндә яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрә торган, кредит оешмаларында ачылган депозит счетларында (кертемнәрендә) калган акчага исәпләнгән процентлар рәвешендә керемнәр булуы (әлеге абзац таләбе 2022 елның 11 гыйнварыннан гамәлдә була);

мөрәҗәгать итүченең һәм/яки аның гаилә әгъзаларының милегендә түбәндәгеләрнең булуы:

гаиләнең һәр әгъзасына исәпләгәндә суммар торак мәйданы 23 квадрат метрдан артып киткән, «торак» һәм «торак төзелмә», «торак йорт» билгеләнеше белән ике һәм аннан артыграк биналар (биналарның өлешләре), «торак» һәм «торак урын» билгеләнеше белән бүлмәләр (бүлмәләрнең өлешләре) (Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, бу очракта законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник чирнең катлаулы формасыннан интегә торган мөрәҗәгать итүче һәм (яки) аның гаилә әгъзасы биләгән торак урыннан (фатирда изоляцияләнгән торак урынның аерым өлешеннән) тыш, шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыннан тыш);

гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә суммар мәйданы 40 квадрат метрдан артып китә торган, «бакча йорты» билгеләнеше белән бер бина;

«бакча йорты» билгеләнеше белән ике һәм аннан күбрәк бина;

«торак булмаган» билгеләнешле бина, «торак булмаган» билгеләнешле бүлмәләр, корылмалар (индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милек булып торган күчемсез мөлкәт объектларыннан, бакчачылык яки яшелчәчелек коммерциясез ширкәтенең гомуми файдалану милеге булып торган мөлкәттән тыш);

транспорт чараларын кую (саклау), ремонтлау һәм алар буенча техник хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән ике һәм аннан күбрәк күчемсез милек объекты (гараж, машина урыны) (өч һәм аннан артык – күпбалалы гаиләләр өчен;

составында инвалид булган гаиләләр өчен; вәкаләтле орган тарафыннан күпбалалы гаиләгә социаль ярдәм чаралары күрсәтү кысаларында авто- яисә мототранспорт чарасы бирелгән гаиләләр);

суммар мәйданы 0,25 гектардан артык китә торган җир кишәрлекләре, ә авыл җирлекләре территорияләре яки авылара территорияләр өчен – бер гектар (гомуми өлешле милектә торган, әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына торган җир кишәрлекләреннән һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән, социаль ярдәм чаралары бирү кысаларында күпбалалы гаиләләргә бирелгән җир кишәрлекләреннән, «Гражданнарга дәүләт яки муниципаль мөлкәттә торган һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан, Ерак көнчыгыш федераль округы составына керә торган җир кишәрлекләрен бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 1 маендагы 119-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш);

гомуми өлешле милектә торган, әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына торган җир кишәрлекләре һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, социаль ярдәм чаралары бирү кысаларында күпбалалы гаиләгән бирелгән, суммар мәйданы гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә 0,20 гектардан артып китә торган җир кишәрлекләре;

ике һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк автотранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр; составында инвалид булган гаиләләр; автотранспорт чарасы вәкаләтле орган тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтү кысаларында бирелгән гаиләләр өчен);

ике һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы (өч һәм аннан күбрәк мототранспорт чарасы – күпбалалы гаиләләр; составында инвалид булган гаиләләр; вәкаләтле орган тарафыннан социаль ярдәм чаралары күрсәтү кысаларында мототранспорт чарасы бирелгән гаиләләр өчен);

двигателенең куәте 250 ат көченнән ким булмаган, чыгарылган елы биш елдан артмаган автотранспорт чарасы, дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаилә алган (сатып алган), биштән артык урыны булган автотранспорт чарасыннан тыш;

чыгарылган елы биш елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк кече суднолар (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була);

чыгарылган елы биш елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк үзйөрешле машина һәм башка төр техника (әлеге абзац таләбе 2022 елның 1 гыйнварыннан гамәлдә була).

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

2.9.1. Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

2.11.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.3.2 пунктының 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәсе бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итела торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша электрон формада алу мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында http://uslugi.tatarstan.ru/, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында алынырга мөмкин.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган барлык кирәкле документларны тапшырганда, үзара ярдәм итешү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең бердәм порталы аша җибәргәндә, турыдан-туры бәйләнешкә керү таләп ителми.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.15.5. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза Үзәк бүлекчәсенә теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлекчәсе белән күпфункцияле үзәкнең үзара хезмәттәшлек итү тәртибе Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган, үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүче белән үзара хезмәттәшлеге күпфункцияле үзәкнең эш регламенты белән җайга салына.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә танықланган документларны һәм мәгълүматны Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша, Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә,

күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә мөмкин.

2.16.5. Бердәм портал яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы гариза биргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 нче бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2 пунктын өстәргә:

«3.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.»;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Мөрәҗәгать итүче айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризаны Үзәк бүлекчәсенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документлар күчермәләрен теркәп тапшыра.

Үзәк бүлекчәсенә почта аша, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша, электрон почта буенча, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынган гариза мөрәҗәгать итүчене

шәхсән кабул иткәндә кабул ителгән гариза һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карала.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.2 пункт өстәргә:

«3.3.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына язмача гариза һәм документлар тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.3 пункт өстәргә:

«3.3.3. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Үзәк бүлекчәсенә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлекчәсе белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсенә җибәрелгән гариза һәм документлар.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.4 пункт өстәргә:

«3.3.4. Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, кергәндә беркетелгән номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап, мөрәҗәгать итүчегә язу тапшыра, гариза почта буенча һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгән очракта, гаризаны теркәү датасы һәм алынганда беркетелгән номеры турында белдерү җибәрә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына гаризаны теркәү турында белдерү җибәрә (гариза Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлекчәсе белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Гаризаны Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталындагы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза һәм документлар Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша килгән очракта яки гариза һәм документлар, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза һәм документлар

(документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.»;

Регламентның 6 нчы бүлеген үз көчен югалткан дип танырга.